ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.02.2024 г. Казань № 3-2/тко-2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024 елга Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасында «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында» 15.12.2023 № 717-42/тко-2023 карары кушымтасына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 27 гыйнварындагы 70 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 16.02.2024 ел, № 3-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024 елга Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында» 15.12.2023, №717-42/тко-2023 карары кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы С.В. Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 717-42/тко-2023
карарына (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
16.02.2024 № 3-2/тко-2024
карары редакциясендә) кушымта

## Татарстан Республикасы территориясендә Көнчыгыш эшчәнлек зонасында «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә 2024 елга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗәдә бердәм тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәте күрсәтүгә чик бердәм тарифлар, сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|
| | | 2024 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| 1 | «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә) <*> | 528,47 | 549,55 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 149 статьясының 2 пунктының 36 пунктчасы кулланылмый.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге